КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2023 ел, 21 февраль

г.Казань

№ 169

«Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 56 һәм 57 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында» 2020 елның 13 мартындагы 279 номерлы карары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Система) турындагы нигезләмәне расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгын – Система булдыруны, аны үстерүне һәм эксплуатацияләүне тәэмин итүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы итеп;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгын – дәүләт әһәмиятендәге эш өлкәсендә Системаны алып баруны тәэмин итүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы итеп;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгын – Системада урнаштырыла торган геодезия һәм картография материалларының актуальлеген тәэмин итүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы итеп;

«Татарстан Республикасының Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесен – Системаның сервер җиһазын һәм программа тәэминатын эшкә сәләтле хәлдә тотуны тәэмин итүче учреждение итеп;

«Татарстан Республикасының Пространствоны планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесен – дәүләт әһәмиятендәге эш өлкәсендә Системаны алып баруга вәкаләтле учреждение итеп;

«Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесен – Системада урнаштырыла торган геодезия һәм картография материалларының актуальлеген тәэмин итүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы функциясен гамәлгә ашыручы учреждение итеп.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының, шәһәр округларының башкарма комитетларына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм әлеге карар нигезендә җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә Системаны эш алып баруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Система булдыруны, аны үстерүне һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына, дәүләт әһәмиятендәге эш өлкәсендә Системаны алып баруны тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 21 февраль, 169 нчы
карары белән расланды

## «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 56 һәм 57 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында» 2020 елның 13 мартындагы 279 номерлы карары (алга таба – 279 нчы карар), «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Пространство мәгълүматы фонды турында» 2018 ел, 14 декабрь, 1133 нче, «Татарстан Республикасының Пространствоны планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесе төзү турында» 2022 ел, 24 гыйнвар, 46 нчы карарлары нигезендә эшләнде һәм «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Система) булдыру, эксплуатацияләү, үстерү тәртибен билгели.

1.2. Бу Нигезләмәдә төп төшенчәләр 279 номерлы карар белән расланган Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларын алып бару кагыйдәләрендә билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.

1.3. Системаның максатлары:

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә территорияләрне үстерү турында, аларга йортлар салу турында, урнашкан һәм урнаштырырга планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектлары турында белешмә, документлар, материаллар һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка белешмә (алга таба – белешмә, документлар, материаллар) берелгән бердәм мәгълүмат киңлеген формалаштыру;

белешмә, документлар, материалларны җыю, документлаштыру, актуальләштерү, эшкәртү, системалаштыру, исәпкә алу, саклау, электрон формада урнаштыру процессларын автоматлаштыру, шулай ук аларны кызыксынучы затларга законнар белән билгеләнгән тәртиптә бирү;

шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә технологик процессларны һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү буенча башка процессларны автоматлаштыру;

шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә рөхсәт бирү документациясен әзерләүнең эчке технологик процессларын формальләштерү һәм камилләштерү;

Татарстан Республикасы территориясендә бертип рөхсәт бирү документларының бертөрле формалаштырылган электрон формаларын куллану;

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү срокларын кыскарту, рөхсәт бирү һәм шәһәр төзелеше документларын әзерләү сыйфатын яхшырту;

башка мәгълүмат системалары, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары – Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып баруның федераль дәүләт мәгълүмат системасы, Бердәм электрон картография нигезен, Торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасын алып баруның дәүләт мәгълүмат системасы, территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасы, федераль мәгълүмат адреслы системасы, «Капиталь төзелеш объектларының проект документациясенә экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестры» дәүләт мәгълүмат системасы, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр» гамәли платформасы белән, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, мәгълүмат алмашуны гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелешен җайга салу процессларында катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (алга таба – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары) арасында мәгълүмати хезмәттәшлекнең сыйфатын яхшырту;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгын һәм үтә күренмәлеген арттыру;

шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә идарә карарларын кабул итүгә мәгълүмати ярдәм күрсәтү;

шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү;

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә коррупция күренешләрен киметү;

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле дөрес белешмәдән, документлардан, материаллардан федераль башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының, физик һәм юридик затларның законнарда билгеләнгән тәртиптә файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү.

## II. Системаның мәгълүмати хезмәттәшлегендә катнашучылар

2.1. Системаның мәгълүмати хезмәттәшлегендә катнашучылар:

оператор – Система булдыруны, аны үстерүне һәм эксплуатацияләүне тәэмин итүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы;

техник оператор – Системаның сервер җиһазын һәм программа тәэминатын эшли торган хәлдә тотуны тәэмин итүче учреждение;

функциональ заказчы – дәүләт әһәмиятендәге эш өлкәсендә Системаны алып баруны тәэмин итүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы;

функциональ оператор – дәүләт әһәмиятендәге эш өлкәсендә Системаны алып баруга вәкаләтле учреждение;

Системада урнаштырыла торган геодезия һәм картография материалларының актуальлеген тәэмин итүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (алга таба – геодезия һәм картография материалларының актуальлеген тәэмин итүгә вәкаләтле орган);

геодезия һәм картография материалларының актуальлеген тәэмин итүгә вәкаләтле орган функциясен гамәлгә ашыручы учреждение;

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә Системаны алып баруга вәкаләтле Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә Системаны алып баруга вәкаләтле органнар);

тәэмин итүчеләр – Системага урнаштыру өчен белешмә, документлар, материаллар җибәрүче федераль башкарма хакимият органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), физик һәм юридик затлар (килешү буенча);

файдаланучылар – Системада урнаштырылган белешмә, документлар, материалларны законнар белән билгеләнгән тәртиптә алырга хокуклы федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар.

2.2. Оператор түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Система булдыруны, эксплуатацияләүне, үстерүне һәм аның эшләвен;

Система булдырганда, аны эксплуатацияләгәндә, үстергәндә һәм аның эшләвен тәэмин иткәндә оештыру, норматив һәм методик яктан тәэмин ителеше булуны;

техник чаралар, программа тәэминаты, элемтә каналлары, Системада эшкәртелә торган мәгълүматны саклый торган техник һәм программа чаралары булуны;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электрон формада дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү, дәүләт функцияләрен һәм муниципаль функцияләрне башкару өчен кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктура турында» 2011 елның 8 июнендәге 451 номерлы карарында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, Системаның башка мәгълүмат системалары, шул исәптән дәүләт системалары белән үзара хезмәттәшлеген;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайт https://portalgisogd.tatar.ru (алга таба – Системаның белешмә порталы) булуны.

2.3. Техник оператор түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Системаны эксплуатацияләүгә һәм аның эшләвен тәэмин итеп торуга, шулай ук техник чараларга, элемтә каналларына, Системада эшкәртелә торган мәгълүматны саклауның техник һәм программа чараларына техник биремнәр һәм (яки) техник таләпләр әзерләүне;

Системаны эксплуатацияләү, үстерү һәм аның эшләвен тәэмин итеп тору буенча эшләр башкаруга һәм (яки) хезмәт күрсәтүгә, шулай ук техник чаралар, элемтә каналлары, Системада эшкәртелә торган мәгълүматны саклауның техник һәм программа чаралары сатып алуга сатып алу процедураларын үткәрүне;

техник (шул исәптән эксплуатация) документация таләпләре нигезендә Системаның сервер җиһазы һәм программа тәэминаты эшләвен;

мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, Системаның мәгълүматлар базаларындагы мәгълүмат сакланышының мәгълүмати иминлеген;

Система функцияләреннән, Системада урнаштырылган белешмә, документлар, материаллардан файдалана алу мөмкинлеге хокукларын чикләү буенча роль моделен кулланып, Системаны алып баруны гамәлгә ашыручы органнарның, тәэмин итүчеләрнең файдалана алу хокукын чикләү;

масштаблау мөмкинлеге белән Системада урнаштырылган белешмәдән, документлардан, материаллардан файдалана алу мөмкинлегенең берничә файдаланучы эшли торган режимы булу;

Системада урнаштырылган белешмә, документлар, материаллар арасында бәйләнешләр булдыру;

Системаны алып баруны гамәлгә ашыручы органнарның, тәэмин итүчеләрнең Системадан файдалану фактлары турында белешмәне теркәү һәм аларны саклауны гамәлгә ашыру, шул исәптән Системада урнаштырылган белешмәгә, документларга, материалларга карата, гамәлләр кылу вакыты, кертелә торган үзгәрешләрнең эчтәлеге, мондый затларның исәпкә алу язулары һәм әлеге гамәлләр кылынган автомат сервислар турында мәгълүмат теркәлә торган Система функцияләренә карата Системаны алып баруны гамәлгә ашыручы органнар затларының, тәэмин итүчеләрнең гамәлләрен исәпкә алу буенча электрон журналны автомат алып бару;

Системада урнаштырылган белешмәнең, документларның, материалларның, шулай ук программа чараларының резерв күчермәсен алу, аларны саклау һәм Системаның эшкә сәләте бозылганнан соң иң күбе 24 сәгать эчендә яңадан торгызу;

Системаның белешмә порталындагы рәсми сайтны эксплуатацияләү, үстерү һәм аның эшләвен тәэмин итеп тору юлы белән, түләү алмыйча, файдаланучыларга Системада урнаштырылган белешмәне, документларны, материалларны бирү мөмкинлеге;

Системаның сервер җиһазын һәм программа тәэминатын эшли торган хәлдә тоту буенча башка чаралар.

2.4. Функциональ заказчы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

дәүләт әһәмиятендәге эш өлкәсендә Системаны үстерүне оештыру, норматив һәм методик тәэмин итү һәм Системаны алып баруны оештыруны;

үз компетенцияләре чикләрендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән срокта Системага белешмә,

документлар, материаллар урнаштыруны оештыруны.

2.5. Функциональ оператор түбәндәгеләрне тәэмин итә:

тәэмин итүчеләрнең Системаны үстерү турындагы тәкъдимнәре нигезендә Системаны үстерүгә ихтыяҗ билгеләүне;

Системаны үстерүгә техник таләпләр һәм (яки) техник биремнәр әзерләүне;

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57 статьясындагы $1^2$ өлеше нигезендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 56 статьясындагы 4 өлешендә каралган белешмәне, документларны, материалларны Системада җыю, документлаштыру, актуальләштерү, эшкәртү, системалаштыру, исәпкә алу, саклау һәм электрон формада урнаштыру юлы белән дәүләт әһәмиятендәге эш өлкәсендә Системаны алып баруны;

үз вәкаләтләре чикләрендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 56 статьясындагы 4 өлешендә каралган белешмәдәге, документлардагы, материаллардагы векторлы киңлек (картографик) мәгълүматлары структурасына методик тәкъдимнәр әзерләүне;

үз вәкаләтләре чикләрендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57 статьясындагы 2 һәм $2^1$ өлешләрендә билгеләнгән срок эчендә Системага белешмә, документлар, материаллар урнаштыруны;

дәүләт әһәмиятендәге эш өлкәсендә Системага урнаштыру өчен кергән белешмә, документлар, материаллар һәм аларны карап тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирелгән белешмәне, документларны, материалларны исәпкә алу реестрын алып баруны;

279 номерлы карар белән расланган Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларын алып бару кагыйдәләрендә каралган нигезләр булганда белешмәне, документларны, материалларны Системага урнаштырудан баш тартуны;

Системада Системаны алып баруны гамәлгә ашыручы органнарның, тәэмин итүчеләрнең файдалана алу мөмкинлеге исәпкә алып барыла торган язуларын булдыруны;

Система алып баруны гамәлгә ашыручы органнарның Системадан файдалана алу мөмкинлеген;

файдаланучыларның Системада урнаштырылган белешмәдән, документлардан, материаллардан файдалана алуны, шулай ук файдаланучыларның аларны алу мөмкинлеген;

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 56 статьясындагы 4 өлешендә каралган белешмә, документлар, материаллар кабул иткән, раслаган, биргән тәэмин итүчеләр тарафыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Системага урнаштыру өчен җибәрү срокларын мониторинглауны;

җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә Системаны алып баруга вәкаләтле органнар тарафыннан Системаны алып баруны координацияләүне;

Системаны үстерү турындагы тәкъдимнәрне функциональ заказчы адресына җибәрүне.

2.6. Геодезия һәм картография материалларының актуальлеген тәэмин итүгә

вәкаләтле орган, геодезия һәм картография материалларының актуальлеген тәэмин итүгә вәкаләтле орган функциясен гамәлгә ашыручы учреждение белән берлектә, түбәндәгеләрне тәэмин итә:

үз вәкаләтләре чикләрендә Системада урнаштырылган яисә урнаштырылырга тиешле геодезия һәм картография материалларының актуальлеген тикшерүне;

үз вәкаләтләре чикләрендә Системада урнаштырылган белешмәдәге, документлардагы, материаллардагы мәгълүматларның геодезия һәм картография материалларының актуальлеген тәэмин итүгә вәкаләтле органдагы (яисә геодезия һәм картография материалларының актуальлеген тәэмин итүгә вәкаләтле орган функцияләрен гамәлгә ашыручы учреждениедәге) мәгълүмат белән туры килү-килмәвен ачыклауны һәм Системаны алып баруны гамәлгә ашыручы органнарга ачыкланган туры килмәүләр турында мәгълүмат бирүне;

функциональ оператор адресына Системаны үстерү турында тәкъдимнәр җибәрүне.

2.7. Җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә Системаны алып баруга вәкаләтле орган түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57 статьясындагы $1^3$ өлеше нигезендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 56 статьясындагы 4 өлешендә каралган белешмәне, документларны, материалларны Системада җыю, документлаштыру, актуальләштерү, эшкәртү, системалаштыру, исәпкә алу, саклау һәм электрон формада урнаштыру юлы белән җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә Системаны алып баруны;

үз компетенцияләре чикләрендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57 статьясындагы 2, $2^1$ һәм 3 өлешләрендә билгеләнгән срок эчендә белешмәне, документларны, материалларны Системада урнаштыруны;

279 номерлы карар белән расланган Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларын алып бару кагыйдәләрендә каралган нигезләр булганда белешмәне, документларны, материалларны Системага урнаштырудан баш тартуны;

җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә Системага урнаштыру өчен кергән белешмә, документлар, материаллар һәм аларны карап тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирелгән белешмәне, документларны, материалларны исәпкә алу реестрын алып баруны;

279 номерлы карар белән расланган Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларында булган белешмәләрне, документларны, материалларны бирү кагыйдәләре нигезендә түләү алмыйча яки түләүгә файдаланучыларның рәсми сораулары буенча Системада урнаштырылган белешмә, документлар, материалларны бирүне;

җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә Системада урнаштырылган белешмә, документлар, материаллар бирү реестрын алып баруны;

функциональ оператор адресына Системаны үстерү турында тәкъдимнәр җибәрүне.

2.8. Тәэмин итүче түбәндәгеләрне тәэмин итә:

үз компетенцияләре чикләрендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57 статьясындагы $1^2$ һәм $1^3$ өлешләре нигезендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 56 статьясындагы 4 өлешендә каралган белешмәне,

документларны, материалларны җыюны, документлаштыруны, актуальләштерүне, эшкәртүне, системалаштыруны, исәпкә алуны һәм Системага урнаштыру өчен электрон формада җибәрүне;

үз компетенцияләре чикләрендә белешмәне, документларны, материалларны Системага урнаштыру өчен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57 статьясындагы 2, $2^1$ һәм 3 өлешләрендә билгеләнгән срокта Системаны алып баруны гамәлгә ашыручы органнарга җибәрүне;

Системага урнаштыру өчен җибәрелә торган белешмәнең, документларның, материалларның дөреслеген, тулылыгын һәм актуальлеген;

функциональ оператор адресына Системаны үстерү турында тәкъдимнәр җибәрүне.

2.9. Файдаланучы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

279 номерлы карар белән расланган Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларында булган белешмәләрне, документларны, материалларны бирү кагыйдәләре нигезендә, кирәк булганда түләү алмыйча яки түләүгә, Системада урнаштырылган белешмә, документларны, материалларны бирүгә рәсми сораулар формалаштыруны;

279 нчы карар белән расланган, шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларында булган, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтлардан файдаланып түләү алмыйча файдаланыла торган белешмә, документлар, материаллар исемлеге нигезендә Системада урнаштырылган, түләү алмыйча файдаланыла торган белешмәне, документларны, материалларны Системаның белешмә порталындагы рәсми сайттан файдалану юлы белән алу мөмкинлеген.

## III. Система структурасы

3.1. Система аның эшчәнлеген, Системаның мәгълүмати хезмәттәшлегендә катнашучыларның вәкаләтләрен башкару мөмкинлеген һәм файдаланучылар өчен Системада урнаштырылган белешмәдән, документлардан, материаллардан файдалана алу мөмкинлеген (алга таба – Системадан файдалана алу мөмкинлеге) тәэмин итә торган веб-приложениеләрдән, модульләрдән һәм компонентлардан тора.

3.2. Системада урнаштырыла торган белешмә, документлар, материаллар составы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 56 статьясындагы 4 өлеше нигезендә билгеләнде.

3.3. Системада урнаштырыла торган белешмә, документлар, материаллар, шул исәптән пространство (картография) мәгълүматлары бирелгән белешмә, документлар, материаллар форматы 279 номерлы карарда билгеләнә.

3.4. Белешмә, документлар, материаллар дәүләт әһәмиятендәге эш өлкәсендәге яки җирле әһәмияттәге эш өлкәсендәге Системада урнаштырыла.

3.5. Системада урнаштырылган белешмә, документлар, материаллар Татарстан Республикасының кадастр бүленеше һәм 279 номерлы карар нигезендә системалаштырыла.

3.6. Системада мәгълүмат алмашу, шул исәптән электрон төрдә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм дәүләт функцияләрен һәм муниципаль функцияләрне башкару өчен файдаланыла торган мәгълүмат

системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктураны кулланып, шулай ук ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдалану юлы белән гамәлгә ашырыла.

3.7. Системада урнаштырылган белешмә, документлар, материаллар ачык була һәм алардан һәркем файдаланырга мөмкин (Россия Федерациясе законнары нигезендә кулланылышы чикләнгән һәм файдаланучыларның алардан файдалана алу мөмкинлеге булмаган мәгълүмат бирелгән белешмәдән, документлардан, материаллардан тыш).

## IV. Система кысаларында мәгълүмати хезмәттәшлек

4.1. Система кысаларында мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар арасында мәгълүмат алмашу электрон формада гамәлгә ашырыла.

4.2. Функциональ заказчыга җирле әһәмияттәге эш өлкәсендәге Система белешмәләреннән, документларыннан, материалларыннан, аларга үзгәреш кертмичә, файдалана алу мөмкинлеге бирелә.

4.3. Функциональ операторга җирле әһәмияттәге эш өлкәсендәге Система белешмәләреннән, документларыннан, материалларыннан, аларга үзгәреш кертмичә, файдалана алу мөмкинлеге бирелә.

4.4. Җирле әһәмияттәге эш өлкәсендә Системаны алып баруга вәкаләтле органга дәүләт әһәмиятендәге эш өлкәсендәге Система белешмәләреннән, документларыннан, материалларыннан, аларга үзгәреш кертмичә, файдалана алу мөмкинлеге бирелә.

4.5. Белешмә, документлар, материалларны Системага урнаштыру, шулай ук аларны теркәү һәм исәпкә алу электрон рәвештә гамәлгә ашырыла.

4.6. Белешмә, документлар һәм материалларны Системага урнаштыру Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57 статьясындагы 2, $2^1$ һәм 3 өлешләрендә билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла.

4.7. Файдаланучыларның Системада урнаштырылган белешмәдән, документлардан, материаллардан файдалана алу мөмкинлеге, түләү алмыйча, Системаның белешмә порталындагы рәсми сайттан файдаланып гамәлгә ашырыла. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Системаның белешмә порталыннан файдаланып, файдалана алу мөмкинлеге гамәлгә ашырыла торган белешмә, документлар, материаллар исемлеге 279 нчы карар белән расланган, шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларында булган, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтлардан файдаланып түләү алмыйча файдаланыла торган белешмә, документлар, материаллар исемлеге нигезендә билгеләнде.

## V. Системаның мәгълүмати хезмәттәшлегендә катнашучылар җаваплылыгы

5.1. Системаны алып баруны гамәлгә ашыручы органнарга, тәэмин итүчеләргә Системага керү өчен өченче затларга авторизация чараларын (криптографик ачкычларны һәм электрон имза ачкычларын компрометацияләүне кертеп) тапшыру тыела.

5.2. Системаны алып баруны гамәлгә ашыручы органнар Россия Федерациясе законнары нигезендә белешмә, документлар, материалларның тулылыгы, дөреслеге һәм аларны Системага үз вакытында урнаштыру өчен җавап бирә.

5.3. Геодезия һәм картография материалларының актуальлеген тәэмин итүгә вәкаләтле орган, геодезия һәм картография материалларының актуальлеген тәэмин итүгә вәкаләтле орган функциясен гамәлгә ашыручы учреждение белән берлектә, Системадагы геодезия һәм картография материалларының актуальлеге өчен җавап бирә.

5.4. Тәэмин итүчеләр Россия Федерациясе законнары нигезендә белешмә, документлар, материалларның тулылыгы, дөреслеге һәм Системага урнаштыру өчен үз вакытында җибәрү өчен җавап бирә.

---